**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЛМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ИГЕНЧЕ АВЫЛЫ ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«23» ноябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Игенче авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2024 елда яшәү урыны буенча Калмаш авыл җирлеге Игенче авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- Игенче авылында су җыю башнясын коймa белән әйләндереп алу.
- Игенче авылында урам утларын ремонтлау

2. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Игенче авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Игенче авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Калмаш авыл җирлеге Башлыгы Ф.В.Шавалиев